СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ

«МИЧУРИНСКОЕ

СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»

ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

«МИЧУРИН

АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»

МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

«20» май 2021ел №14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск шәһәре прокурорының «Торак» илкүләм проектын тормышка ашыруны регламентлаучы 2021 елның 16 апрелендәге 02-08-02 номерлы закон таләпләрен тиешенчә үтәмәү турындагы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң, Мичурин авыл җирлеге советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктны «территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары,» сүзләреннән соң «комплексلы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру буенча документлар проекты буенча,» сүзләре белән тулыландырырга;

3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.1. Территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыру өчен җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта, җирле администрация башлыгы карары нигезендә, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча һәм комплекслы үсеш алырга тиешле территорияне планлаштыру документлары проекты буенча гавами тыңлаулар һәм (яки) җәмәгать фикер алышулары үткәрү рөхсәт ителә.»;

5 пунктта «территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары,» сүзләреннән соң «комплекслы үсешкә тиешле территорияне планлаштыру буенча документлар проекты буенча,» сүзләре белән тулыландырырга;

6 пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү әзерләнгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

2.Әлеге карарны Мичурин авылы, Совет ур., 26 – административ бина, Совет ур., 28 - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк урамы, 9 - мәдәният йорты бинасы, Үзәк урамы, 15 - мәктәп бинасы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Р.Ә Иванова